ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘТӘС
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423737, Әтәс авылы, Үзәк ур., 75 а йорты

СОВЕТ АТЯСЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423737, село Атясево, ул. Центральная,
д. 75 а

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«16» ноябрь 2019 ел** **№ 27**

Әтәс авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 7 августындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Әтәс авыл җирлеге территориясендә 2020 елда бер тапкыр түләнә торган салымның 18 яшькә җиткән, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр гражданнан, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәткә бәйсез рәвештә, 2020 елда бер тапкыр түләү кертүгә сез, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 1 төркем инвалидлардан (аларның саны җирлек халкының гомуми санынннан 30 процентан да артмый), җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, 500 (биш йөз) сум күләмендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү турында:

- су челтәрләрен ремонтлау, тоту, су чыганакларын лицензияләү;
-урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;
-юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдлау, кардан чистарту)
-йорт төзелеше һәм ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;;
- зират коймасын ремонтлау;
- Күмү урыннарын документаль рәсмиләштерү;
-рәсми спорт һәм мәдәни чараларны оештыру һәм уздыру;;
- Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;
- һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү, обелиск төзү;;
- Бикчәнтәй авылындагы ФАП бинасында су белән тәэмин итү һәм чокырны төзекләндерү;;
- гидротехник корылмаларга декларацион тикшерү үткәрү.

2. Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында Әтәс авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәсен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлеге"бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Әтәс авыл җирлеге башлыгы Э.Ф.Насыйрова